| ЛЕНИНОГОРСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

6.08.2021 г.Лениногорск № 46

Лениногорск шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 14 октябрендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 387.2 статьясы нигезендә Лениногорск шәһәр Советы карар бирде:

1.Лениногорск шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 14 октябрендәге 8 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

- балалар-яшүсмерләр автомобиль мәктәпләре автодромнарын урнаштыру өчен даими сроксыз файдалануга бүлеп бирелгән җир кишәрлекләренә карата исәпләнгән салым суммасының 50 % күләмендә ташлама билгеләргә.

2.Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетасында, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры Р.Г.Хөсәенов